**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**

05.03.2019

**БОЕРЫК**

№53

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә булган затларның чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмалардан, сәяси фиркалардан, башка төрле иҗтимагый оешмалардан һәм дини берләшмәләрдән хөрмәт билгесе, махсус исемнәр, бүләкләр кабул итеп алу тәртибе турында

2004 елның 27нче июлендәге 79нчы номерлы ФК «Россия Федерациясе дәүләт  гражданлык хезмәте турында» дип исемләнгән Федераль канун, 2015 елның 10нчы октябрендәге 506нчы номерлы «Россия Федерациясенең кайбер дәүләт вазыйфаларын башкаручы һәм аерым бер федераль дәүләт хезмәтен башкаручы затларның чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмалардан, сәяси фиркалардан, башка төрле иҗтимагый оешмалардан һәм дини берләшмәләрдән хөрмәт билгесе, махсус исемнәр, бүләкләр алу тәртибе

турында нигезләмәне раслау турында» дип исемләнгән Россия Федерациясе Президенты Указы, 2016 елның 12нче гыйнварындагы УП-5 номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт вазыйфаларны башкаручы, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән һәм вазыйфадан азат ителә торган затларның чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмалардан, сәяси фиркалардан, башка төрле иҗтимагый оешмалардан һәм дини берләшмәләрдән хөрмәт билгесе, махсус исемнәр, бүләкләр алу турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, б о е р ы к бирәм:

1. Беркетелгән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы (моннан соң – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә булган затларның чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмалардан, сәяси фиркалардан, башка төрле иҗтимагый оешмалардан һәм дини берләшмәләрдән хөрмәт билгесе, махсус исемнәр, бүләкләр кабул итү турындагы тәртипне расларга.

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт секторына, әлеге Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан дәүләт хезмәтендәге затларны әлеге боерык белән таныштырып чыгарга.

3. Мәгълүмати үсеш һәм медиа секторына әлеге Боерыкны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тоту буенча Министрлык эшләре белән идарә итүче Э.М.Әхмәтгәрәевны җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **Д.И.Фаттахов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
боерыгы белән расланган
05.03.2019 №53

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу Нигезләмәсе

1. Әлеге Нигезләмә тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан, әгәр Министрлыкның гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керә икән, чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус исемнәрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр) (фәнни исемнәрдән тыш) алу тәртибе билгеләнә.

2. Министрлыкның гражданлык хезмәткәре исем, бүләкләр алган чакта Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрының (алга таба – министр) рөхсәтен алырга тиеш

3. Министрлыкның исем, бүләк алган яисә чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма, дини берләшмәдән аны алачагы турында белдерү алган гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алырга рөхсәт итү турында әлеге нигезләмәнең 1нче кушымтасындагы форма буенча төзелгән үтенеч (алга таба – үтенеч) язып бирә.

Үтенечне карау вакыты үтенечне әлеге Нигезләмәнең 8 пункты буенча

дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторда теркәгәннән соң 10 көн тәшкил итә.

4. Исем, бүләк алудан баш тарткан гражданлык хезмәткәре дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга өч эш көне эчендә чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында әлеге Нигезләмәнең 2нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән белдерү кәгазен (алга таба – белдерү кәгазе) тәкъдим итә.

5. Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча министр карар кабул иткәнче

министрлыкның исем, бүләк алган гражданлык хезмәткәре исем, бүләккә документларның төп нөсхәсен һәм аңа караган документларның төп нөсхәсен

аларны алганнан соң өч көн эчендә җаваплы саклауга дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәнең 3нче кушымтасында тәкъдим ителгән форма буенча төзелгән алыш-биреш акты төзелә.

6. Гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләк алган яисә аңардан баш тарткан очракта, гариза яисә белдерү кәгазе бирү вакыты Министрлыкның гражданлык хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән санала башлый.

7. Әгәр гражданлык хезмәткәре аңа бәйле булмаган сәбәпләр аркасында гариза яисә белдерү кәгазе бирә, исем, бүләккә документларның, аларның документларының төп нөсхәләрен әлеге Нигезләмәнең 3,4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаса, әлеге сәбәп беткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча гариза яисә белдерү кәгазе бирергә, исем, бүләккә документларның, аларның документларының төп нөсхәләрен тапшырырга тиеш.

8. Гариза яисә белдерү кәгазен теркәү дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор тарафыннан бирелгән көнне әлеге Нигезләмәнең 4нче кушымтасындагы форма буенча төзелгән теркәү журналында ясала. Теркәлгән гариза яисә белдерү кәгазен дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор ике эш көне эчендә карау өчен министрга җибәрә.

9. Оештыру эше секторы ике эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре буенча министр кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм аңа бүлек мөһере белән расланган гаризаны (белдерү кәгазе) күчермәсен министр резолюциясе белән тапшыра. Министр резолюциясе белән гаризаны (белдерү кәгазе) оригиналы дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш секторына тапшырыла һәм төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

10. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәренең гаризасын министр канәгатьләндергән очракта эшләр идарәчәсе 10 эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә исем документларын, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәсен тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәнең 3нче кушымтасы буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәренең гаризасын министр канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор 10 эш көне эчендә исемгә караган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тиешле чит ил дәүләте органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, башка иҗтимагый берләшмәгә, дини берләшмәгә җибәрә.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрына
___________________________________
_______________________________дан
(Ф.И.Аи., биләгән вазыйфасы)
___________________________________

Чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешма
һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен,
бүләген алуга рөхсәт итүне сорау турында
үтенеч

Миңа _______________________________________________________________________

(нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә, күрсәткән нинди

_____________________________________________________________________________

хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

_____________________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләккә документлар бирелүнең датасы һәм урыны)

_____________________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

алырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

Мактаулы яисә махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар,

(кирәклесе астына сызарга)

_________________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

_________________________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләккә документлар атамасы)

20__елның __ «_____» нан №__лы кабул итү-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының оештыру эшләре секторына тапшырылды.

«___» __________ 20___ ел ______________ ________________________

(имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
2нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрына

___________________________________
______________________________дан
(Ф.И.Аи., биләгән вазыйфасы)
___________________________________

Чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында белдерү кәгазе

___________________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)
___________________________________________________________________________.
(нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә, нинди күрсәткән хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

алудан баш тартуым турында карар кабул итүемне белдерәм.

«___» _____________ 20___ ел __________ __________________________
(имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләре, халыкара
оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый оешмалар
һәм дини берләшмәләрнең
мактаулы һәм махсус
исемнәрен, бүләкләрен алу
тәртибе турындагы
Нигезләмәгә
3нче кушымта

Кабул итү-тапшыру акты

«_____»____________ 20___ ел №_______

Без, түбәндә имза куючылар, әлеге актны түбәндәге хәл турында төзедек,
___________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы) тапшырды/ кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының эшләр идарәчесе
__________________________________(вазыйфасы,Ф.И.А..и) түбәндәгеләрне тапшырды/ кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга):

| № п/п | Атамасы | Саны (шт.) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды
______________________
(имза) (имзаны аныклау)

Кабул итте
______________________
(имза) (имзаны аныклау)